| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятерниинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2023 Девәтернә авылы № 30-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советының «Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү тәртибе турында» 05.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны алдан юридик тикшерү һәм федераль законнарны мониторинглау, хокукый анализ, хокукый җайга салу юлларын мониторинглау нәтиҗәләре буенча Кодексның АИС системасы - Региональ законнар аналитигы ярдәмендә муниципаль норматив хокукый актка туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советының «Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү тәртибе турында» 05.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 пунктның 2 абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)” сүзләре белән алыштырырга

2) 11 пунктның 1 абзацында “Татарстан Республикасы Президентына” дигән сүзләрне “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)” дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендта игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Э.Э. Ганиев